СОВЕТ МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

16.12.2015г　　　　　с. Майдан　　　　　№ 4 - 28

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Мәйдан авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Мәйдан авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләр буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юлламасы белән риза булырсызмы:

- Мәйдан авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү: 600 метр зиратны койма белән әйләндереп алу.

ӘЙЕ　　　　　　　　ЮК.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　В. В. Михеев